ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
22 март 2023 ел

КАРАР
№ 62

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны туплану урынын (урыннарын) булдыру һәм кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 № 89-ФЗ, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 №7-ФЗ, «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 23.11.2009 № 261-ФЗ Федераль законнарга ярашлы рәвештә, 06.10.2003 № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Татарстан Республикасының 28.07.2004 ТРЗ№45 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 № 2314 «Тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм аларны урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары ягыннан җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында Кагидә раслау турында»карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә файдаланган терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) билгеләргә: ЖЧЖ «Ципьинское МПП ЖКХ» гараж бинасы, Чепья авылы, Дмитровская урамы, 20 йорт.
2. Милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган күпфатирлы йортларда тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган, кулланучылар файдаланган терекөмешле лампаларны туплану урыннары яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 № 2314 карары белән расланган кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.
3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терегөмешле лампаларның туплану урыннары, әгәр күпфатирлы йортларда терекөмешле лампаларның

туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаса, бу йортларда кулланучылар файдаланган терекөмөшле лампаларны туплану урыныны да булып тора.
4. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә терекөмөшле лампалар тупланган урынның (урыннарның) урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.
5. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә терегөмөшле лампаларны беренче җыю һәм вакытлыча урнаштыру урынын билгеләү турында» 22.12.2021 №42 карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми (baltasi.tatarstan.ru) һәм Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Чепья авыл җирлеге
башкарма комитеты житэкчесе: И.Н.Галиев